**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «30» маеннан № 23-175

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында
бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары (2020 елның 4 июнендәге 61-381 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 6-34 номерлы, 2021 елның 8 сентябрендәге 13-102 номерлы, 2021 елның 9 декабрендәге 16-128 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Бюджет процессы принциплары» исемле 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«- гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

- унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга.».

1.2. «Бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары» исемле 16 статьяның өченче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы финанс елы башына район бюджеты акчаларының калган өлеше:

хисап финанс елында файдаланылмаган муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә, шулай ук район Советының хокукый акты белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса өзеклекләрен каплауга һәм хисап финанс елында әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә район исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга, финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен

кирәкле сумма чикләрендә күрсәтелгән максатларга файдаланылмый торган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә башкарыла торган юридик затларга субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренә юнәлдерелә ала, район Советының бюджет турындагы карарында каралган очракларда;

хисап финанс елында район бюджетын үтәү барышында бюджет ассигнованиеләрен тулысынча файдаланмауга бәйле барлыкка килгән калган акчалар арасындагы аермадан артмаган күләмдә бурыч тотрыклылыгы югары яисә уртача булган заемщиклар төркеменә әлеге Кодекс нигезендә кертелгән заемщик бюджетын үтәү барышында барлыкка килгән һәм бюджет ассигнованиеләрен арттыруның әлеге өлешнең икенче абзацында каралган суммасында Район вәкиллекле органының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә кулланыла;

- Бюджет Кодексы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемщиклар төркеменә кертелгән Район алынмаларының гомуми суммасыннан, җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы йомгаклары буенча Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып киткән күләмдә агымдагы финанс елында районның бурыч йөкләмәләрен кыскарта торган түләүләрне башкаруга җибәрелә.»

1.3. «Районның муниципаль бурычы структурасы» исемле 17 статьяның 23 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында район тарафыннан бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган йөкләмәләр күләме;"; (РФ БК 100 статьясы нигезендә)

1.4. 21 статьяның 2 өлешендә «Муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме» сүзләреннән соң «районның бурыч йөкләмәләре» сүзләренә «тиешле ел азагына файдаланылмаган инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының калдыгы күләменнән тыш» сүзләрен өстәргә,».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http//pravo.tatarstan.ru , Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http:// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов